**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

422750, село Большая Атня, улица Ш.Марджани, дом 6

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Ш.Мәрҗани урамы, 6нчы йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31 гыйнвар 2025ел. № 30

**Татарстан Республикасы Әтнә районы башкарма комитетының 17.12.2024 ел 527нче номерлы “2025 елга Әтнә муниципаль районында торак-коммуналь хезмәтләргә тарифларны раслау турында” гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 156 статьясы, 158 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлауга кертемнең минималь күләмен билгеләү турында» 2013 елның 29 июнендәге 450 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында» 2024 елның 27 декабрендәге 1229 номерлы карары нигезендә Әтнә район башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитетының 17.12.2024 ел 527нче номерлы “Әтнә муниципаль районында торак-коммуналь хезмәтләргә 2025 елга тарифларны раслау турында” гы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Карарның 2 нче кушымтасын яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карар 01.01.2025 елдан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (https://atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Әтнә район башкарма комитеты урынбасары М. Л. Халиковка йөкләргә.

Җитәкче А. Ф. Каюмов

Әтнә район башкарма комитетының
31 гыйнвар 2025 ел №30
карары редакциясендә
Әтнә районы башкарма комитетының
17.12.2024 ел № 527нче карарына
2 нче кушымта

**НИГЕЗ СТАВКАСЫ**

торак урыныннан файдаланган өчен (наемга база ставкасы) торак урыннарны яллаучылар өчен муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре

| Түләүнең исеме | Хезмәтне үлчәү берәмлеге | Хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге өчен база ставкасы (сумнарда) | |
|---|---|---|---|
| | | 01.01.2025елдан 30.06.2025елга кадәр | 01.07.2025 елдан 31.12.2025 елга кадәр |
| Яллау буенча база ставкасы | торак урынының гомуми мәйданның кв.м. өчен айлык түләве | 8,47 | 8,47 |